Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

28.11.2025 Менделеевск ш. № 751

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының «Татарстан
Республикасы Менделеевск муниципаль
районының ситуация үзәген төзү турында»
2020 елның 29 маендагы 326 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнарында ситуация үзәкләренең кадрлар үзгәрешләренә һәм аттестация сынауларына әзерләнүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының ситуация үзәген төзү турында»2020 елның 29 маендагы 326 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә.

1.1. Карарның 3 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Менделеевск муниципаль районы ситуация үзәге эшчәнлеге турында хисаплылык рәвешен 2 нче кушымта нигезендә расларга. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад, сәнәгать һәм эшкуарлыкка ярдәм итү бүлегенә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы ситуация үзәге эшчәнлеге турында кварталга 1 тапкыр хисап тапшырырга.»

1.2. Карарның 4 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад, алгарышлы социаль  икътисади үсеш территориясен һәм эшкуарлыкны үстерү буенча урынбасарын Менделеевск муниципаль районының ситуация үзәген төзү һәм эшләтеп җибәрү өчен җаваплылык үзәге итеп билгеләргә.»

1.3. Карарның 9 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

"Ситуация үзәгенең мәгълүмат ресурсларын саклау урыны итеп ситуация үзәге администраторының локаль эш урыны итеп билгеләргә.»

1.4. Карарның 10 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад, сәнәгать һәм эшкуарлыкка ярдәм итү бүлегенә җаваплы бүлекчәләр җитәкчеләре белән берлектә бер ай эчендә:

мәгълүмат ресурслары һәм мәгълүмати-аналитик модельләр паспортларын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аларны Татарстан Республикасы бүленгән ситуация үзәгенең мәгълүмати ресурслары һәм мәгълүмати-аналитик модельләре реестрларына кертергә;

Менделеевск муниципаль районының ситуация үзәгендә мәгълүмат ресурсларын һәм мәгълүмати-аналитик модельләрне формалаштыру һәм актуальләштерү регламентын эшләргә һәм раслауга кертергә;

эштә файдаланыла торган мәгълүмат ресурсларын Менделеевск муниципаль районы ситуация үзәге белешмәләре базасына кертергә һәм аларның актуальләшүен тәэмин итәргә, шулай ук алга таба мәгълүмати-аналитик модельләр эшләве өчен кирәкле башлангыч белешмәләрнең актуальләшүен тәэмин итәргә;

мәгълүматлар базасы һәм модельләр администрациясе өчен җаваплы хезмәткәрләрне беркетергә.»

1.5. Карарның 13 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад, алгарышлы социаль икътисади үсеш территориясен һәм эшкуарлыкны үстерү буенча урынбасарына йөкләргә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Менделеевск муниципаль районының мәгълүмат сайтында урнаштырырга (https://mendeleevsk.tatarstan.ru) «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад, алгарышлы социаль икътисади үсеш территориясен һәм эшкуарлыкны үстерү буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Искаков